ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 18 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяда:

а) 1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәһәр һәм авыл торак пунктлары чикләре торак пунктлар җирләрен башка категориядәге җирләрдән аерып торалар. Шәһәр һәм авыл торак пунктлары чикләре муниципаль берәмлекләр чикләрен кисеп чыга алмый яисә аларның чикләреннән чыга алмый, шулай ук гражданнарга яисә юридик затларга бирелгән җир кишәрлекләре чикләрен кисеп чыга алмый. Шәһәр йә авыл торак пунктлары чикләренең җир кишәрлекләре чикләрен кисеп чыгуы ачыкланганда, мондый кисеп чыгуны бетерү Россия Федерациясе Җир кодексы һәм башка федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

б) 3 пунктта «торак пунктлар» сүзләрен «шәһәр һәм авыл торак пунктлары» сүзләренә алмаштырырга;

в) 9 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 12 статьяда:

а) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пунктча өстәргә:

«$1^1$) дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлар;»;

б) 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 15 статьяның 2 пунктында «мондый җирләрдә җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләр башкару» сүзләрен «мондый җирләрдә җир асты байлыкларыннан файдалануны гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты 2024 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 23 декабрь
№ 132-ТРЗ